РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава Балыклы-Чукаевского сельского поселения
Рыбно-Слободского муниципального района
индекс 422655 , с.Балыклы-Чукаево ,ул. Центральная, дом 8 телефон

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге башлыгы
индекс 422655, Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк ур., 8 йорт
телефон

Тел.: (84361) 26357, факс: (84361) 26357, эл.адрес: Blc.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Балыклы-Чүкәй ав. № 11 3 ноябрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең Керәшен Казысы авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең Керәшен Казысы авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2022 елның 23 ноябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең Керәшен Казысы авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, өлешчә мобилизацияләүгә бәйле рәвештә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- торак пунктлар чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;

- авыл җирлеге чикләрендә кышкы юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу );
- су системасы очен су күтәрү насосы алу
“ЯКЛЫЙМ”                                        “КАРШЫ”
5.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй  авыл җирлегенең  Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балыклы-Чүкәй авылы,Үзәк урамы,8 йорт; Иске Арыш авылы, Үзәк урамы, 23а йорт; Керәшен Казысы авылы, Титов урамы, 11Б йорт адреслары буенча урнашкан  махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.
6. Карар басылып чыккан  (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Башлыгы                                        И.С.Мазитов